КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 ноябрь г.Казань № 894

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә теркәлгән 4 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 4 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү: | | | | |
| 3.1. | Социаль-психологик консультация үткәрү, шул исәптән гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга эчке проблемаларын, шәхесара бәйләнеш проблемаларын хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтү, социаль-психологик проблемаларны кисәтү һәм җиңеп чыгу, шул исәптән эчке ресурсларны мобилизацияләү юлы белән. Эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри белем алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү турында мәгълүмат һәм консультация бирү | консультацияләр | 1 | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| 3.2. | Психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы шәхесе үзенчәлекләре җыелмасын тикшерү, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки тергезү шартларын билгеләү, социаль-психологик ярдәм чаралары исемлеген эшләү, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның һөнәри мәнфәгатьләрен, омтылышларын, сәләтләрен ачыклау өчен һөнәри юнәлешне билгеләү диагностикасын үткәрү | чаралар комплексы | 3 | социаль хезмәт күрсәтү чоры |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы өчен төп когнитив һәм психик функцияләрне (хәтер, диккать, коммуникативлык һ.б.) торгызуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга эмоциональ | курс | 1 | социаль хезмәт күрсәтү чоры». |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | хәлендәге һәм үз-үзен тотышындагы тайпылышларны бетерүгә яки киметүгә формалаштыруга юнәлдерелгән тернәкләндерү чараларын үткәрү, социаль-психологик проблемаларны хәл итү, универсаль адаптацион психологик күнекмәләрне (коммуникатив, үз-үзен тикшерүдә тоту, үз-үзен җайга салу, стрессларга бирешмәүчәнлек һ.б.) үстерү, белем алуга һәм эшкә урнашуга карата мотивациясен үстерү һәм күз аллауларын дөрес юнәлештә үзгәртү, төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (диагностика нәтиҗәләре буенча) яңа шартларга адаптацияләнү өчен шәхси алшартлар формалаштыру | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\894.docx